ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 18а йорт, Кече
Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatfr.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 7** **26 октябрь 2020 ел**

«Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 һәм 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 9 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Ташкичү авылы, Ташкичү торак пункты. Чишмә урамы, 28А адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы кырыенда Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Ташкичү торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2020 елның 10 ноябренә 10.00 сәгатькә билгеләнде.

Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ташкичү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

Ташкичү торак пункты Чишмә урамының юл-урам челтәрен ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

2. Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

«Ташкичү авыл җирлеге»
муниципаль берәмлек башлыгы Р.К.Вәлиев